**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.01.2017 № 21-75-12

Казан ш.

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын раслау турында” 05.02.2015 ел, № 21-75-6 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында” 3 июль, 2016 ел, № 318-ФЗ Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә һәм административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген һәм процессуаль документларның үрнәк формаларын раслау турында” 05.02.2015 ел, № 21-75-6 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

1.1 пунктчасының беренче абзацында “ 19.5 статьясының 7 өлеше” дигән сүзләрне “ 19.5 статьясының 7 һәм 7.3 өлешләре” дигән сүзләргә алыштырырга;

1.2 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.29.3 статьясында, 7.32 статьясының 4,5, 8-10 өлешләрендә, 15.1, 15.11, 15.14 – 15.15.16, 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4.1 статьясы, 19.5 статьясының 20, 20.1 өлешләрендә, 19.6 статьясында, 19.7 статьясында, 19.7.2 статьясындагы 1 өлешендә, 19.26 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган хокук бозулар составлары буенча:”;

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.29.3 статьясында, 7.32 статьясының 8 – 10 өлешләрендә, 15.1, 15.14 – 15.15.16

статьяларында, 19.5 статьясының 20 өлешендә, 19.7.2 статьясының 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозулар турында эшләрнең түбәндәгеләр тарафыннан карап тикшерелүен билгеләргә:”.

Министр Р.Р.Гайзатуллин